**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Иске Мавринавыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 136** **10.12.2018 ел**

**«Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 104 номерлы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

# КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 104 номерлы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.11 пунктчасында «38,75» санын «56» санына алмаштырырга.

2. «Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 104 номерлы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 26 ноябрендәге 134 номерлы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Иске Маврин авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **В.М.Михайлова**